# Татарстан яшьләре

N 11

(8733)

ПӘНҖЕШӘМБЕ

28 гыйнвар, 1993 ел

Бәясе килешү буенча.

• ЯШЬЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ • 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА •




Бу көннәрдә Казан шәһәр Советы халык депутатларының чираттагы сессиясе бара. Көн тәртибенә шәһәр транспортын үстерү, Казанның генераль планын эшләү, хосусыйлаштыру турындагы һәм башка мөһим мәсьәләләр кертелгән. Сессиянең беренче көнендә Югары Совет Рәисе Ф.Мөхәммәтшин катнашты һәм депутатларга республика тормышындагы төп юнәлешләрне аңлатты. Аерым алганда, ул үткән елны шау-шулы митинглардан гамәли эшкә күчү елы булуын әйтте, бүгенге иң мөһим мәсьәләләргә тукталды. Соңыннан парламент җитәкчесе депутатларның күпсанлы сорауларына җавап тотты.

Рәсемнәрдә: сессия кызу булырга охшаган.

Евгений КАНАЕВ фотолары






**Россия ваучерларын алырга өлгермәгән яки теләмәгәннәр өчен аларны бирү срогы озайтылды.** Шулай итеп, саклык банклары 15 февральгә кадәр "байлык" өләшүне дәвам итәчәк.

**Хәзер тимер юл вокзалында пассажир поездларына билетларны паспорт белән генә бирәләр.** Бу чара билетлар белән сату итүчеләргә чик кую максатыннан чыгып эшләнә. Хәзер поездлардагы проводникларга , билетка теркәлгән фамилия белән паспорттагы мәгълүматлар туры килмәгәндә, билет бәясе кадәр штраф салу хокукы бирелде.

**Чаллыда озакламый телефон-автоматлардан шалтырату түләүсез булачак.** Инде берничә шундый аппарат эшли дә башлады. Шәһәр телефон челтәре җитәкчелеге кулланыштан төшеп кала баручы 15 тиенлекләр урынына махсус жетоннар эшләп чыгару һәм ватык телефоннарны алыштыру артык кыйммәткә төшәчәк дигән нәтиҗәгә килде. Яңа телефон-автоматларда еш ватыла торган трубкалар да юк: алар урынына тавышны көчәйткеч аппаратлар урнаштырыла.

**Татарстанда яшәүче бала-чага да озакламый чын курчаклар белән уйный башлаячак.** Казандагы уенчыклар фабрикасы балаларның күңелен кайтаручы ташкурчаклар белән бергә дөньяда танылган "Барби" курчаклары җитештерә башлый. Әлеге уенчык АКШта эшләнгәннән ким булмас дип көтелә. Иң әһәмиятлесе - аның бәясе дә бүген кибетләрдә, киоскларда сатыла торган "Барби"ларныкыннан ике мәртәбә очсызрак булачак.

**Озакламый Казанга ике катлы өч "Икарус" кайтып җитәчәк.** Алар Будапештта махсус заказ буенча эшләнгәннәр. Татарстан дәүләт байрагы төсендәге автобусларның беренче катында бәдрәф, багаж бүлеге, шоферларның ял бүлмәсе һәм кабина урнашкан, ә өстәге катта - пассажирлар өчен урыннар һәм буфет. Халыкара экологик стандартларга туры китереп эшләнгән мондый автобуслар Татарстанга тагы да кайтарылачак.

**Түбән Кама халкы чишмә суы эчә башлады.** Рәхәт тормыштан түгел, билгеле. Уфа предприятиеләренең эчәр суыбызны фенол белән әледән-әле агулап торуы шәһәр халкы өчен су проблемасын китереп чыгарды. Хәзер биредә артезиан скважиналары бораулау эшләрен дәвам итә.

## Чаллыдан саллы хәбәрләр

Хәзер бары тик миллионерлар гына КамАЗ эшләп чыгара торган "Ока" җиңел автомобильләрен сатып алачак. Кайчандыр 3 мең сум торган машинаның соңгы бәясе тәп-төгәл 979 мең.

* * *

Чаллы үзгәртеп корылачак. Мэрия каршындагы төзелеш комитеты шәһәр уртасында калган Орловка авылын реконструкцияләү масьәләсен карады. Төзелеш 215 гектарда барачак.

Бүгенгә Орловка аша үтә торган автотранспорт магистрале санитария һәм юл хәрәкәте кагыйдәләренә җавап бирми. Биредә яшәүчеләр өчен җүнле тормыш-көнкүреш шартлары да юк.

* * *

Чаллыда качаклар саны артканнан - арта бара. Эш белән тәэмин итү үзәге каршында оешкан миграция комитетына 877 гаилә мөрәҗәгать иткән инде. Аларның 266сы - Таҗикстаннан, Үзбәкстаннан - 132, Азербайҗаннан - 26, Молдовадан - 7 гаилә теркәлгән. 505 гаилә якын-тирәдәге авылларга урнаштырылган. 74 - тулай торакларда яши. Яңадан 98 гаиләгә бүлмәләр әзерләнә. Качакларга ваучерлар һәм азык-төлек талоннары бирү оештырылган.

* * *

Русия хөкүмәте чигенергә мәҗбүр булды. СССР таркалгач, ул варис буларак КамАЗның 25 процент акциясен алып калган иде. Завод җитәкчеләре һәм Татарстан хөкүмәте бергәләп тырыша торгач, Русия хөкүмәте бу акцияләрне камазлыларга бирергә булды.

* * *

Татарстан Республикасының Тышкы икътисадый элемтәләр министрлыгы үзенең стратегик товарларны экспортка чыгару хокукын КамАЗның тышкы сәүдә фирмасына бирде. Бу фирма чуен, кара металл прокаты, аларның калдыклары кебек товарларны читкә чыгара алу мөмкинлеге белән чит ил партнерларын да кызыксындыра ала.

* * *

КамАЗ акционерлык җәмгыяте 1992 елда 78 миллиард 89 миллион сумлык товар җитештергән. Бу алдагы ел белән чагыштырганда 10 миллиард 354 миллионга кимрәк. Конвейердан 82000 "КамАЗ", 4514 "Ока" төшкән. Авыр йөк машиналарының саны 1991 ел белән чагыштырганда 9802 данәгә кимегән, ә "Ока"лар саны 1400гә арткан.

## Жириновский башкисәрләре бүген Гыйракка сугышырга китә, ә иртәгә кайда?..

*"Ирекләләр" - мина шартлатучылар һәм диверсия операцияләре буенча белгечләр. Болар, имеш, Америка империализмына каршы сугышучылар. "Без Кувейтның берничә портын һәм самолетын шартлатачакбыз", - дип белдерде Жириновский Англиянең "Санди таймс" газетасы журналистларына.*

*Жириновский Багдадка китүчеләрнең терроризм белән шөгыльләнүләрен яшереп тә маташмый хәтта. Боларның террорчылар булуы билгеле булса да, илдән тоткарлыксыз чыгу өчен аларга бернинди каршылык та юк. Алай гына да түгел, самолетка утырыр алдыннан халыкара аэропортта телекамералар каршында "спектакль" дә оештыралар. Терроризмга каршы көрәш буенча инде әллә ничә халыкара документка кул куйган Россия властьлары фашистлар юлына ни өчендер аркылы төшми (Россиянең үз эчендәге республикаларга каршы бу "патриотларны" куллану перспективасы күз алдында тотыладыр, мөгаен).*

*Эчке эшләр министрлыгының хокук департаменты экспертларының әйтүе буенча, имеш, Россиянең җинаятьләр кодексында мондый гамәлләр өчен җавап бирү каралмаган. Ялланып сугышучыларга каршы көрәш буенча БМО Генассамблеясы сессиясе 1990 елда кабул иткән халыкара конвенциягә, имеш, Россия кул куймаган. (Монысына куймаса, терроризмга каршы кабул ителгән әллә никадәр документка кул куйган бит, югыйсә).*

*Россия властьлары бөтен дөньяда аның үзенең үк абруена тап төшерүче акциягә чик куймадылар. Гыйракка җибәрү өчен Жириновский озакламый инде 400 кешедән торган батальон тупларга җыена. Мөгаен, ул моны бернинди каршылыксыз башкарып та чыгар.*




**Пермь өлкәсе, Барда районы мәдәният көннәре Арча районында аеруча зур күтәренкелек рухында үтте. Моның сере шул: Г.Тукайның бабасы Зиннәтулла чыгышы белән Барда төбәгеннән булган. Ул Өчиле авылында мулла булып торган мәчет әле дә исән. Тик ул бик искергән. Барда урманчылык хуҗалыгы якташлары эшләгән мәчетне реставрацияләү өчен агач алып килгәннәр. Мәчетне төзекләндерү эшен алар тулаем үз карамакларына алганнар. Бардалылар шул ук көнне Кенәр азык комбинаты, Арча милли аяк киеме берләшмәсе, "Октябрь" колхозы белән таныштылар. Кунаклар Арчада зур концерт куйдылар, ә Өчиледә "Карт гашыйк" спектаклен күрсәттеләр.**

Рәсемдә: кунаклар Г.Тукай музее белән танышалар.

**М.ШАКИРҖАНОВ фотосы.**



### Җиләге дә шәп, телевизоры да могҗиза

Японнарның дөньяда иң шәп электрон аппаратура эшләп чыгаруларын бот буе малай-шалай да белә хәзер. Алар - иң кечкенә телевизорны эшләүчеләр дә. Дөньяда бүген иң кечкенә һәм иң җиңел телевизорны (рәсемдә) эшләүче - "Касио" фирмасы. Телевизор инде сатуга да чыккан. Аның биеклеге - 9,1 см, киңлеге - 6 см, калынлыгы - 2,4 см, ягъни мәсәлән, телевизор сигарет пачкасы зурлыгында. Экранының диагонале - 3,57 см, телевизорның авырлыгы - 170 грамм.

Ә менә бу эре җиләкне "Нэшнл", "Панасоник", "Текникс" маркалы аппаратлары белән дан тотучы "Мацусита Дэнки" корпорациясе үстергән.

**ИТАР-ТАСС фотосы.**

Чаң сугабыз

# Генераллар безне төп башына утыртмакчы

Удмуртиянең Камбарка шәһәре Башкортостан һәм Татарстан республикалары белән янәшә урнашкан. Бу кечкенә провинцияне тирә-яктагы күрше районнарда яшәүчеләрдән башка белүче дә юктыр, мөгаен. Кызганыч, әлбәттә. Чөнки шушы люизит шәһәрчегенең нәкъ үзәгендәге хәрби базада агулы матдәләрнең бөтендөнья (6,4 мең тонна) запасы тупланган.

Исәпләүләргә караганда, биредәге тиз тәэсир итә торган әлеге агу Удмуртиядә яшәүче һәрбер кешене 175 миллион (!) мәртәбә үтерергә җитә. Ләкин фаҗига булган очракта удмуртларга гына килмәячәк ул үлем. Моннан 2 гасыр элек атаклы Демидовның оныклары төзеп калдырган бүгенге Камбаркадагы шартлау бөтен Урал регионын, андагы эре промышленность үзәкләрен харап итәчәк. Ул гына да түгел, якыннан гына агып ятучы Кама елгасы буйлап Татарстанга, Идел буе өлкәләренә афәт китерәчәк.

Генерал Кунцевич үзенең бер чыгышында Камбаркада люизитны эшкәртеп, мышьяк җитештерү заводы төзү башланачагы турында әйткән иде. Люизит дип аталган бу агу моңарчы хәрби максатларда кулланылса, мышьяк дигәне исә промышленность-көнкүреш кирәк-яраклары өчен файдаланылачак. Бер агудан икенче агу җитештерә торган завод төзелүе турында хәбәр иткәннән соң шәһәр халкына (республикада яшәүчеләргә түгел) этаплап-этаплап химик коралларны юкка чыгару буенча комплекслы программа проектын җиткерделәр. Ә аның буенча фикер алышу өчен нибары ике көн вакыт бирелде. Менә шушы проект халыкның сабырлык канатларын сындырды да инде. Хезмәт урыннарында үлем объектын төзүгә каршы җыелышлар уздырылып, кешеләр үзләренең конкрет фикерләрен әйттеләр. Хәзерге вакытта генерал Кунцевич җитәкчелегендәге конвенциональ комитетның берьяклы карарына протест йөзеннән халык арасында имзалар җыю бара.

Камбаркалылар гадәттән тыш куркыныч зонада ярты гасыр гомер кичерәләр. Илле ел буе кешеләр агулы һава сулап яшиләр.

Тикмәгәмени бу шәһәрдә яшәүче халыкның нинди авыру белән авыруы турында берниндн мәгълүмат та юк. Ә авырулар хәрби базада 1960 елларда - иприт, 1980 елларда люизит агуын ачык юл белән яндыру аркасында барлыкка килгән. Генералларга андый статистика кирәк түгел. Ләкин Камбаркада хәрби химикларның иҗат эшчәнлеге буларак барлыкка китерелгән һәйкәл ролен хәрби часть урнашкан райондагы саргайган һәм үле урман полосасы үти.

Биредәге халыкның пассивлыгына өметләнеп һәм җирле республика һәм район хакимиятенең ризалыгын алгач, генераллар озак вакыт үзләренең чын йөзләрен ачмый тордылар. Башта люизитны кечкенә күләмдәге савытларга тутырабыз һәм аны кеше яшәми торган урыннарга алып китеп юкка чыгарабыз дип ышандырдылар безне. Аннары әлеге кечкенә савытларның чыдамлыгын билгеләү буенча сынау уздырылуын һәм аларның берниндн дә зыян китермәячәген хәбәр иттеләр. Ә инде соңрак Кунцевич бер генә карарның да халык ризалыгыннан башка башкарылмаячагына берничә мәртәбә басым ясап әйтте. Халык аның вәгъдәләренә чын күңелдән ышанды. Ни дисәң дә, академик, күп премияләр белән бүләкләнгән галим алдашмас бит инде! Ләкин Кунцевич оятсызларча алдашты. Җирле хакимият җитәкчеләре дә шушы ук уенны уйнадылар. Алар шәһәр кешеләреннән яшертен генә Камбаркада люизитны кабат эшкәртү һәм юкка чыгару программасын тормышка ашыру буенча акционерлык җәмгыяте төзергә рөхсәт бирделәр. Ә Кунцевич исә мондый "игелеклелек"не яхшы бәяләде: аларны акционерлык җәмгыятен оештыручылар рәтенә кертергә вәгъдә итте. Генерал әлеге программа өчен акчаны үзе бүлә һәм үзе үк таратып та бирә. Кем әйтмешли, үзе баш, үзе түш.

Кешеләрне куркыныч хәлләрдән саклау өчен, билгеле, инспекторлык итү хезмәте дә кирәк. Бу максатка барлык чыгымнардан 495 миллион доллар (!) өлеш чыгарылган. Шуның өстенә Мәскәүдәге Милли үзәк тә арзанга төшми. Әйе, чиновниклар үзләре турында кайгырта беләләр, анысы. Кабинетларны җиһазлау өчен генә дә 10 миллион америка доллары бүленгән. Әгәр бу сумманы безнең акчаларга әйләндерсәң! Аның каравы, завод үзе китергән зыян өчен компенсация түләүгә Удмуртиягә 150 миллион "агач" берлекләр (былтыргы бәя белән) вәгъдә итте. Хәтта шушы сумманы Камбаркада яшәүче халык саны буенча бүлсәң дә, һәр кешегә, тәвәккәллек өчен, нибары 7,5 мең сум акча тия. Дәүләт биргән әлеге сәдакага (анысы да бүгенгә генә ярый) үзеңне соңгы юлга озату өчен бер тартма аракы да ала алмыйсың. Тик шунысы ачык: сәдаканы бер үк кеше бирә һәм талап та ала.

Хәзер кешеләргә җир сатып алырга рөхсәт итәләр. Әмма шушындый зонада калгач, безнең заводларыбыз кемгә кирәк булыр? Агулы калдыклар белән капланып беткән, ризык үстерергә сәләтен югалткан җирләребезнең кемгә хаҗәте калыр? Генерал Кунцевич үзе шәхси дачасын биредә төзергә ризамы икән соң? Камбаркада яшәүчеләрнең хәтта бүтән шәһәргә китеп урнашырга да мөмкинлекләре юк бит. Чөнки берkem дә бирегә фатир алыштырып килергә теләми. Генераллар әнә шулай төп башына утырттылар халыкны.

Хәрби базага америкалы кунакларны ипи-тоз белән каршылап керттеләр. Люизит турында кино төшерүче немецларга да агу саклау урыннарындагы соңгы кадаклшөрепләргә кадәр күрсәттеләр. Ә удмурт галимнәрен бирегә якын да китермиләр. Югыйсә, бөтен исәп-хисап, күзәтү-тикшерү эшләре белән Мәскәүдән яисә чит илдән килгән белгечләр түгел, ә үзебезнекеләр шөгыльләнергә тиешләр бит.

Камбарка халкы Урал буе регионының халык күп яши торган бу төбәгендә агулы матдәләрне кабат эшкәртү заводы төзү "идея"сен җинаять дип саный. Һәм безгә бөтенләй дә аңлашылмый: ни өчен химия җинаятьләре өчен чаң суккан татар галиме Вил Мирзаяновка җинаять эше ачтылар? Ни өчен мондый кабахәтлекләр өчен менә шушы Кунцевич кебек генераллар җавап тотмый?

**В.ВЕДЕРНИКОВ,**
**В.МЕРЗЛЯКОВ,**
**Камбарка район Советы депутатлары.**
**Удмуртия.**

***Редакциядән.** Әлеге язма газетага әзерләнеп беткән көннәрдә Татарстан Югары Советының экология һәм табигать ресурсларыннан рациональ файдалану буенча даими комиссиясе рәисе А.Колесник журналистлар белән пресс-конференция уздырды. Анда сүз нәкъ менә шушы мәкаләдә кузгатылган гыйбрәтле проблема турында барды. Бары тик ведомство мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы генерал А.Кунцевич һәм аның тарафдарларын "үлем объекты" территориясендә яшәүче халыкның язмышы кызыксындырмый. Русиянең 7 регионында урнашкан хәрби складлардан җыйналган химик коралларны Камбаркага илтүче тимер юл Татарстан аша узса да, бу хакта безнең халык һәм хөкүмәт белән берниндн сөйләшү уздырылмаган. Әгәр шушы юлларда төрле сәбәпләр аркасында авария була калса, бу фаҗига өчен кем җавап тотар?*

*Даими комиссия рәисе депутат А.Колесников шушы хакта Югары Советка комиссия исеменнән чаралар программасы эшләп бирелүен һәм аның буенча тиешле карар кабул ителәчәген әйтте. "Ә инде Татарстан Югары Советы карарын санга сукмыйча, химик коралларны безнең территория аша күчерүгә юл куелса, мин җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать итеп, иң элек үзем рельска утырачакмын", - диде Алексей Алексеевич. Эш аңа ук барып җитмәс дип өметләник.*




### *Бердәнбер булма икән*

*Исәнме "О.Т."! Гаиләдә бер бала булу кыен икән ул. Әти-әни, әби-бабайның күзе гел миндә генә. Алар соң кайтсам да кайгыралар, ашамасам да борчылалар. Иптәш малайларның рәхәт исмасам, өй тулы бала-чага булгач, артларыннан берkem дә сагаламый. Минем дә, үскәч, ким дигәндә 5 балам булачак.*

**РИНАТ, 15 яшь.**
**Мөслим районы.**

### *Бетолар бездә дә бетмәгән*

*Бу кызлар гел егетләрдән генә зарланалар. Имеш, безгә "Байлар да елый" телесериалындагы Марианнаның улы Бето кебек булу өчен бер пот тоз ашарга кирәк. Мактану кебек булса да әйтим инде, мин нәкъ менә шул Бетога охшаган. Мин дә эчмим, тартмыйм, сүгенмим, кыскасы, менә дигән егет.*

**Ф.**
**Пермь өлкәсе. Уинск районы.**

### *Ялгызлыкка ни җитә?*

*Минем кайбер көннәрдә океаннар айкыйсым, айда буласым һәм тагын әллә кайларга барасым килә. Мондый көннәрдә үз-үземә урын таба алмыйча йөдәп бетәм. Минем Робинзон Крузо кебек ялгызым гына утрауда яшисем килә. Юкса, минем дус-ишләрем дә күп, тиз аралашам да.*

**ФӘНИС.**
**Минзәлә районы.**

### *Егетләргә каршы килә алмыйм*

*"О.Т."! Мин быел мәктәпне тәмамлыйм. Исәбем - Казанга укырга китү. Әмма мине бер нәрсә борчый. Мин егетләргә һич тә каршылык күрсәтә алмыйм. Әти-әни яныннан киткәч, бозык юлга кереп китмәсәм ярар иде. Егетләр авызыннан чыккан һәрбер сүздән эреп төшмәс өчен миңа нинди таләпләрне үтәргә икән?*

**А.Т.**
**Чирмешән районы.**

### *Тавышлы дәрес*

*Безне химиядән өлкән яшьтәге Г. апа укыта. Ул шундый тырыш, белемле һәм кешелекле укытучы. Тик аның дәресендә укучылар тавышланып утыралар. Укытучыга аның дәресендә тавыш яки тынычлык булуга карап бәя бирү һич тә дөрес түгел дип уйлыйм. Һәр сыйныфта да тәртипсез малайлар бар, әмма алар усал укытучыларның дәресендә генә тыныч утыралар. Бөтен укытучылар да акыра - бакыра, суга, куркыта белми шул.*

**РАВИЯ.**
**Балык Бистәсе районы.**

### *Бертөрлелек туйдырды*

*Сәлам, "О.Т."! Сиңа дүрт кыз хат яза. Без үзара бик дус яшибез. Һәр кичне очрашабыз, сөйләшәбез, магнитофон тыңлыйбыз. Кызык кебек тоелса да, гел бер төрле генә яшәү туйдыра икән. Безгә хәзер 17 яшь бит инде. Киләчәк турында әле беребезнең дә уйлап караганы юк. Бертөрлелектән ничек котылырга икән?*

**СӘРИЯ, ӘЛФИЯ, РИММА, РОЗАЛИЯ.**
**Мамадыш районы.**

### *Баянда уйнарга өйрәнәм*

*Баянда уйнарга өйрәнә башладым. Музыка мәктәбендә укымаган кеше аңларлык нота китабы эзлим. Китап җибәрүчеләр булса, акчасыннан тормас идем.*

**РАФАЭЛЬ.**
**(Адресым редакциядә).**

### *Ялындырмакчы идем...*

*Бу хатны аптыраудан язам. Кышкы каникулда киногa бардым. Кайтканда А. исемле кунак егет озатты. Икенче көнне дә килгән иде, әмма мин, ялындырмакчы булып, өйгә кереп киттем. Хәзер үкенәм, тик терсәк җитми тешләргә. Кызлар, берүк, ялындырам дигән булып, минем хәлдә кала күрмәгез.*

**Л.**
**Биектау районы.**



**"Әни, әгәр мине цинк табутта кайтарсалар, син нәрсә эшләр идең?"**

# ҮЛМӘ, РАФИЛ!

## АРМИЯ ҮТЕРГӘН ЕГЕТ СОЛТАНЫ ТУРЫНДА

Фотодагы егеткә карагыз әле. Рафил Хәбибуллинга 18 яшь. Көчле беләкләренә чыдаша алмыйча күлмәк җиңнәре тартылып тора, ә карашы - итагатьле, хыялый. Дус-ишләре аны хөрмәт итә. Сөйгән кызы да бар. Шат күңелле, спортны яратучы бу егет үз-үзенә нык ышана. Шуңа да аның күзләреннән шатлык, нур бөркелә. Рафил ышана: тормыш - яхшы!

Армиягә китәр алдыннан Рафил бу фотоны әнисенә тапшырганда болай дигән: "Әни, әгәр мине цинк табутта кайтарсалар, син нәрсә эшләр идең?" Әни кеше бу сорауга нәрсә дип җавап бирсен инде: лып итеп диванга утырган да телсез калган.

Хәбибуллиннар йортында соңлап кына дөньяга килгән берданбер малайга игътибар зур булган. Аны игелекле, гадел итеп үстерергә тырышканнар. Рафил шундый булып үскән дә. Кыйммәтле келәмнәргә, алтын-көмеш әйберләренә исләре китмәүче ата-ана уллары яхшы кеше булып үссен өчен барысын да эшләргә тырышкан. Рафил да аларны гел шатландырып кына торган: яхшы укыган, йөзү буенча югары күрсәткечләргә ирешкән. Хәтта Казансуны тыныч кына аркылыга йөзеп чыга алган. Өйдәге эшләрдән дә йөз чөермәгән - табак-савыт, идән юган, кер үтүкләгән. Кечкенәдән үз акчасын булдырган. Каникулларны еш кына әнисе эшләгән заводта үткәргән. Вагон бушатырга да йөргән.

Баянда, гитарада уйнаган, җырлаган, шигырьләр язган, рәсем ясаган. Талантлы егет үзенең көтелмәгән сюрпризлары белән туганнарын, дусларын әледән-әле шатландырып яшәгән. Тикмәгә генә Рафилның дус-ишләре Хәбибуллиннар фатирының ишегенә: "Монда безнең президент яши", - дип язып куймаганнардыр инде. Йортта улының дус-ишләрен һәрвакыт ачык йөз белән каршы алганнар. Әнисе малайлар арасындагы соңгы яңалыклардан гел хәбәрдар булып яшәгән. Гомумән, Рафил бервакытта да әнисеннән сер яшермәгән. Сөйгән кызына багышлап язылган беренче шигырен дә ул иң элек әнисенә укып күрсәткән, беренче тапкыр үбешүләрен дә яшермәгән хәтта. Әнисенең күз алдында гашыйк та була ич ул! Шул җәйдә Рафил 360 сум акча эшли һәм әнисе белән теплоходта сәяхәткә китә. Шунда Г. белән таныша. Ул чакта аңа - 16, ә кызга 15 яшь була. Һәрбер тукталышта ул аңа зур чәчәк бәйләмнәре бүләк итә. Г. башка шәһәрдән булгач, Рафил соңыннан да аның янына бик еш барып йөри.

Яшүсмер вакытта Рафилга да күп тапкырлар "Казан феноменын" татырга туры килә. Унынчы класста ул хәтта авылга кайтып укырга мәҗбүр була. Группировкаларга йөрүче малайлар аңа берничә ел буе "баллы тормыш" вәгъдә итеп карасалар да, теләкләренә ирешә алмыйлар.

"Ни өчен җирдә шулкадәр күп гаделсезлек? - дип еш кына сорый торган булган Рафил. - Мин шуның белән көрәшергә телим". Рафил гаделсезлеккә күз йома белмәгән: нәрсә уйласа, шуны әйтеп биргән. Икейөзлелекне сөймәү нәселдән киләдер, күрәсең. Хәбибуллиннар нәселендәге ирләрнең күбесе милициядә эшлиләр. Рафилның әтисе Әсхәт абый да милиционер. Мондый холыклы кешеләргә хәзер тормышта ни дәрәҗәдә кыен икәнлеген ул яхшы белә. Әмма Рафилның кечкенәдән үз сүзе була: "Мин дә үз сүземне әйтергә телим. Мин нәрсә уйлаганымны әйтергә тиеш".

Авылда вакытта ул әнисеннән аерып ябылган бозауның мөгрәгәненә түзә алмыйча өч көн буе шуның янында кайнаша. Рафил бозау белән сөйләшә, аны иркәли, сыйпый, тынычландыра.

Аквариумдагы балыкларның да телен аңлаган ул. Аларның һәркайсына дусларының исемнәрен куша һәм андагы хәлләргә аңлатма биреп әнисен рәхәтләндереп көлдерә. "Эдгар, син нигә Регинага таба йөзәсең?"

Рафилны армиягә озату кичәсе дә туйдан ким булмый. Ул өстәлдәге сый, андагы кеше, аларның шатлыклы авазлары! Читтән торып институтта укыган, теләсә көндезге бүлеккә дә күчә алган егеткә армиядән калу мөмкинлеге дә була. Тик Рафил иң якын дустына болай ди: "Чын ир-егет булу өчен армиягә барырга кирәк".

1991 елның 8 июнендә армиягә китә. Мәскәү янында хезмәт итә. Пешекче була. Сугышчан әзерлектәге уңышлары өчен мактау кәгазе ала. Әти-әнисе аны ант кабул иткән көнне башлап җырлаучы ролендә күрәләр. Күрешкәч, Рафил әнисенең алдына башын куя һәм тыңлый да тыңлый. Армиядән соң үзенең Югары милиция мәктәбенә керәчәклеге турында әйтә. Моңсу гына аерылышалар. Әнисе акрынлап улының армиядән кайтуына әзерләнә башлый. Матур күлмәк, шарф, аяк киеме сатып ала. Фәкать бер ел гына түзәргә дә...

Ә бу вакытта Рафил үзенең иптәшләренә менә нәрсәләр яза: "Хәзергә, әлбәттә, барысы да бик авыр. Өйгә кайтасы килә. Армиядә ниләр булганын алдан ук белгән булсам, мин төрле юллар белән бармый калу ягын караган булыр идем". Яки: "Читтән караганда, кешечә яшәү өчен бөтен шартлар да тудырылган кебек. Ял бүлмәсендә телевизор, магнитофон, аидео, тутый кош һәм ике аквариум бар. Спорт бүлмәсе дә җиһазландырылган. Әмма бу өстенлекләрдән мин бер ел хезмәт иткәннән соң гына файдалана алам".

Сөйгәнен кайгыга саласы килмәсә дә, аңа язылган хатларда да армиядәге пычраклыклар ялтырап киткән. "Әле бер ел хезмәт итмәсәм дә, бөтен гомеремә җитәрлек пычраклык һәм вәхшилек күрдем". "Мондый шартларда кемнең кем икәнлегенә тиз төшенәсең. Тик бу "танышулар" өчен минем алгы тешләрем җитми башлады инде... Нервылар да какшады". "Армия - тормыш итү өчен яхшы мәктәп, әмма аны читтән торып кына үтәргә кирәк", - дип дөрес әйткәннәр икән".

Рафилны Наро-Фоминскидан Мәскәү тирәсендәге Нахабино поселогына күчергәч, сөйгәненә ул болай дип яза: "Мин чын тәмугка эләктем. Һич тә кешеләрнекенә охшамаган бу тормышны кәгазьгә төшерүе дә кыен. Хәзер минем алда ике юл бар - йә ничек тә түзәргә, йә асылынырга. Аз хезмәт итүем өчен һәр адым саен мыскыл һәм җәбер көтә. Тагын ярты ел шундый шартларда яшисем бар. Тик мин иркен сулап яши башлау көннәре килүенә ышанам әле".

Рафилга бу көннәрне күрергә насыйп булмый. 26 август көнне Хәбибуллиннар гаиләсе улларының үлеме турында телеграмма алалар. Диагноз - йөрәк-кан юлларындагы кискен хәлсезлек. Рафилның әнисе Әлфия апа үз-үзенә ышанмый тора. Ә бу вакытта аның улы офицерларның көлүе астында җан бирә. Мәрхүмнең гәүдәсен Казанга кайтарган Азнакай егете Радик Әлфия апага менә нәрсәләр сөйләгән. Рафил кич белән санинструктор булып эшләүче якташы Радик янына санчастька килгән. Тагын кереп чыгарга вәгъдә итеп чыгып китүенә 20 минут вакыт та үтми, Радикны частька чакыралар. Нашатырь спиртын иснәтүнең дә файдасы тими. Санинструктор "ашыгыч ярдәм" чакырырга кирәклеген әйтә. Бу күренешне карап торган офицерлар көлә башлыйлар. Янәсе, бер сугуда ике метрлы егетне үтерергә мөмкинмени? Әйе, егетләр уйныйлар да, шаяралар да, үзара көч тә алышалар. Бу хәлне үз күзләре белән күреп торган солдатларның әйтүе буенча, Рафилга армиягә кадәр бокс белән профессиональ шөгыльләнгән солдат суккан булган.

Рафил "ашыгыч ярдәм" машинасы белән госпитальгә барганда җан бирә. Әлеге "боксер"ны тикшерү эшләре барган чакта Мәскәүнең данлыклы "Матросская тишина" төрмәсенә утырталар. Тикшерү эшләре тәмамланмаса да, Рафилның соңгы минутларын күргән шаһитлар дәшмәүне кулайрак күрә башлаганнар. Ә теге — йөрәк-кан юлларындагы " кискен хәлсезлек" дигән диагноз яшь солдатның үлеменә гаепле булган кешеләрне яшереп калырга да бик мөмкин.

Рафилны соңгы юлга озатырга бик күп кеше җыела. Әлфия апаның эш урыныннан гына да, ай азагы булуга да карамастан, бик күп хезмәттәшләр килә кайгы уртаклашырга.

Менә безнең җәмгыять тагын бер мәхәббәт һәм бәхет утраучыгын - Хәбибуллиннар гаиләсен җимерде. Шат, дус һәм беркемгә дә начарлык кылмаган, гаделлек һәм намус дигән төшенчәләргә табынып яшәгән гаиләдә зур кайгы. Хәтта мәетне озатырга кайткан офицер, теләсә нинди гаепләү һәм авыр сүзләр ишетергә әзерләнеп кайтса да, бер генә кырын караш та сизмәгән бу гаиләдә. Рафил хезмәт иткән частька барып "тикшерү" үткәрергә җыенган егетләрне дә әтисе туктатып кала. Гадел, тырыш, игътибарлы һәм кече күңелле бала үстергән өчен җәмгыять үзләреннән ачы көлсә дә, алар авыр минутларны сабыр гына үткәреп җибәргәннәр.

"Әгәр Рафилны үтерүчеләр тиешле җәзаларын алмасалар, мин милициядә эшләгән барлык хезмәтемне сызып ташлыйм", - ди Әсхәт абый. "Үз гомеремдә беркемгә дә начарлык теләмәдем, ә хәзер миндә ниндидер күрәлмаучылык яши", - дип офтана Әлфия апа да. "Мин Рафилның армиягә баруын бик теләгән идем. Ә хәзер дустымның түгел, дошманымның да анда баруын теләмим", - ди Рафилның туганы Рамил Хәбибуллин.

"Рафил булмагач, нигә яшибез?" - ата-ана шулай уйлый. Бу йортта башкарылган һәр эш, уй-фикер Рафил белән бәйләнгән булган. Улының балалары яшәргә тиеш булган бүлмәләрдә дә тынлык. Әлфия апа почта алган саен газета арасыннан улының хаты килеп чыкмасмы дип көтә. Йөрәк пәрәсе әле дә исәндер кебек тоела. Төштә дә, өндә дә гел ул гына. Күптән түгел генә Рафил әтисенең төшенә кергән һәм шаяртып кына подъезддагы пычраклык турында әйткән. Иртә белән әтисе җиденче каттан беренчегә кадәрле баскычларны себереп чыккан. Үзе себерә, үзе елый... Ә Рафилның дусты ваннада йокыга киткәч, аны да дусты яңагына сугып тончыгудан саклап калган.

Әлфия апа хәзер улының дус-ишләре, хезмәттәшләренең олуг ярдәме, игътибарлыгы аркасында гына яши. Аны бер генә сәгатькә дә ялгыз калдырмыйлар. Әлфия апа моның өчен аларга бик зур рәхмәтле.

Рафил үзенең соңгы хатында үзенә гел ак төстән генә торган ботинка, джемпер, костюм алырга кушкан булган. "Мин ап-актан киенеп кенә кунакка йөриячәкмен..."

Миңа калса, Рафилның теләге чынга ашты. Аны бик озак еллар сагынып искә алачаклар әле. Аның чиста күңеллелеген, гаделлек сөюен, игътибарлы, итагатьле булуын, шат елмаюын онытып булырлыкмы соң? Бер генә тапкыр үзен күрүчеләрнең дә ул мәңге хәтереннән чыкмас, истәлекләренә көтелмәгән кунак булып килеп керер.

**Венера ЯКУПОВА.**



***Рәсемнәрдә:** Рафил Хәбибуллин армиягә менә шундый кыяфәттә китте һәм менә шулай кайтты.*

## Котлыйбыз!

**Укучыларыбыз игътибарына!**

**Газетада котлау турында белдерү бастыру өчен редакция счетына 200 сум акча күчерергә һәм акча күчерү турындагы квитанция белән котлау текстын редакция адресына җибәрергә кирәк.**

* * *

Питрәч районы, Татар Казысы авылында яшәүче кадерле әниебез Хәлимә Гайсә кызы Галиуллинаны туган көне белән котлыйбыз. Гомер буе ул тегү теккән, бәйләгән. Биш баланы тәрбияләп үстергән. Кадерле әниебез, дәү әниебез, без сиңа озын гомер, саулык-сәламәтлек һәм бәхет телибез.

**Кызларың, улың, кияүләрең һәм оныкларың.**

* * *

Сарман районының Иске Минзәләбаш авылында яшәүче әниебез Бибиҗиһан Галимовага гыйнвар аенда 85 яшь тула. Әниебезне чын күңелдән туган көне белән тәбрик итәбез, аңа исәнлек-саулык, бәхетле картлык, әткәй белән тигез гомер итүләрен телибез.

**Иң изге теләкләр теләп: кызың, киявең, киленнәрең, оныкларың.**

* * *

Балык Бистәсе районының Олы Елга авылында яшәүче кадерле әниебез Зәкия Сәләхетдин кызы Гибазовага бу көннәрдә 50 яшь тулды. Без кадерле әниебезне чын күңелдән олы юбилее белән котлыйбыз. Киләчәктә аңа корычтай нык сәламәтлек, кояштай озын гомер, балаларының игелеген күреп гомер кичерүен телибез.

**Иң изге теләкләр белән: кызың, улың, киявең, оныкларың.**

* * *

Алексеевск районының Урманасты Шенталасы авылында яшәүче әтиебез Марс Гарифуллинга бу көннәрдә 57 яшь, әниебез Гөлсирәгә 54 яшь тулды. Кадерле әтиебез һәм әниебез! Сезне олы бәйрәмегез белән кайнар котлыйбыз. Кайгы-хәсрәт күрмичә, таза-сау озын гомер итегез.

**Иң изге теләкләр белән: балаларыгыз, киявегез, киленегез, оныкларыгыз.**

* * *

Кайбыч районының Салтыган авылында яшәүче әниебез Хәлимә Рәхимулла кызы белән әтиебез Зарифҗан Газимҗан улы Газимҗановларның бергә тормыш итә башлауларына бу көннәрдә 45 ел булды. Кадерле әти-әниебез! Без сезне зур бәйрәмегез белән кайнар котлыйбыз. Сезгә кояштай озын гомер, корычтай нык сәламәтлек, кайгы-хәсрәтсез, шатлык белән бергә-бергә тату гомер итүегезне һәм мул тормышта яшәвегезне телибез. Безнең сезгә рәхмәтебез чиксез.

**Улларыгыз, кызларыгыз, кияүләрегез, киленегез һәм оныкларыгыз**

# ҮЗ ТИҢӘМНЕ КӨТӘМ

***Укучыларыбыз игътибарына! Редакциянең танышу хезмәтеннән файдаланган өчен түләү бәяләре үзгәрде.***

***Газетада танышу турында белдерү бастырып чыгару өчен редакция счетына 100 сум, "номер"га хат язган өчен 50 сум күләмендә акча күчерергә һәм акча күчергәнлек турындагы квитанция белән хатны редакция адресына җибәрергә кирәк. Редакция "номер"ларга хатларны үзе тапшыра, ләкин аларның җавап хаты язуларын гарантияләми һәм адресларын хәбәр итми. Акча күчерү турында квитанциясе булмаган танышу хатлары газетада басылмый һәм "номер"ларга тапшырылмый. Хатларыгызда тулы адресыгызны, исем-фамилиягезне, сез танышырга теләгән кешенең номерын язарга онытмагыз. Шулай ук, башка кешеләр исеменнән танышу хезмәтенә хат язмавыгызны сорыйбыз.***

### ИЮ-484

Миңа 29 яшь, буем 155 см. Физик кимчелекләрем юк. Тулай торакта яшим, начар гадәтләре булмаган, төпле уйлы, пөхтә, 28-32 яшьләрдәге, буе кимендә 165 см булган татар ир-егетеннән фотосурәт салынган хат көтәм.

### СЗ-486

Тәртипле гаилә корырга теләүче ир-егет белән танышырга телим. Миңа 36 яшь, буем 158 см, милләтем татар, югары белемле, кияүдә булмадым.

### ХГ-627

Миңа 62 яшь, буем 164 см. Авылда үз йортымда яшим. 8 ел элек тол калдым. Мал-туар асрыйм, умартачылык белән шөгыльләнәм. Үзем сау-сәламәт, начар гадәтләрем юк. Минем янга күчеп килергә риза булган 55-65 яшьләрдәге хатын-кыз хат язса, аңлашыр идек дип уйлыйм. Картлык көнебездә бер-беребезгә таяныч булыр идек.

### АР-629

Мин 25 яшьләрдәге (буем 167 см), өйләнмәгән, шат күңелле, тыныч холыклы, аракы эчү белән мавыкмаган, авылда үз йортында торучы татар егете. Минем кебек ялгызлыктан туйган, 20-23 яшьләрдәге хатын-кыз белән гаилә корыр идем.

### БГ-488

Мне 24 года, рост 168 см. Живу в Казани с родителями. Интересы разносторонние. Познакомлюсь с молодым человеком, не злоупотребляющим спиртным, добрым и внимательным, желательно жителем города Казани. Национальность значения не имеет.

### ХГ-490

Миңа 36 яшь, буем 169 см. Милләтем татар. Авылда туып-үстем, хәзер шәһәрдә яшим. Ирем 3 ел элек вафат булды. 12 һәм 9 яшьлек ике улым бар. 3 бүлмәле фатирда әнием белән яшибез. Үзем аш-су әзерләргә, җыр-музыка тыңларга, бәйләргә яратам. Мине тиң күрерлек, балаларымны чит итмәслек, гаиләдә бер-берене аңлап, ышанып, хөрмәт итеп, таяныч булып яшәрлек ир-ат белән танышырга телим. 34-42 яшьләрдәге, татар яки башкорт милләтеннән булган, аракы эчү белән артык мавыкмаган ир-егетнең җавабын көтәм. Хатыны үлгән, балалары булган ирләр дә хат язсалар ярый.

### НМ-492

Мин 23 яшьлек, шат күңелле татар кызы. Буем 162 см. Сабыр холыклы, гаиләдә тугрылыклы, аракы эчми торган, бер-берене хөрмәт итеп, ярдәмләшеп яшәргә теләге булган, 30 яшьтән артмаган татар егете белән танышырга телим.

### БА-494

Миңа 33 яшь, буем 155 см. Махсус урта белемле. Бухгалтер булып эшлим. Авылда туып-үстем, хәзер дә шунда яшим. Кияүдә булмадым. Булачак тормыш иптәшемне кешеләр белән аралашучан, хөкем ителмәгән, тормышта барлык яктан да терәк булырлык, 33-36 яшьләрләге, буе кимендә 170 см булган татар ир-егете дип күз алдына китерәм. Үз йорты яки фатиры булса, бигрәк әйбәт. Фотосурәтләр белән килгән хатларга җавап бирәм.

### ЗФ-496

Миңа 29 яшь, буем 165 см. Милләтем татар. Авылда туып-үстем, хәзер Казанда яшим. Кияүдә булдым, баласыз юк. Үзем бар нәрсә белән дә кызыксынам, барлык эшләрне дә яратып башкарам. Тәскә-биткә зарланырлык түгел, үземне сөйкемле, чибәр диләр. Сабыр, хатын-кызны хөрмәт итүче, бер-береңә таяныч булып яшәрлек, аракы эчү һәм тәмәке тарту белән мавыкмаган, 27-35 яшьләрдәге, берәр баласы булган, сау-сәламәт, эш сөючән, уен-көлкене аңлаган, буе кимендә 170 см булган чын ир-ат мине күңеленә якын итсә, бездән дә бәхетле кеше булмас. Хат язучыларны җавапсыз калдырмам.

### ХГ-631

Миңа 61 яшь, буем 162 см. Хатыным вафат булды. Аракы эчмим, тәмәке тартмыйм. Авыл җирендә яшим, аз булса да мал-туар асрыйм. II группа инвалид. 59-60 яшьләрдәге, әдәпле, авыл җирендә яши торган хатын-кыз белән танышыр идем.

### ГЗ-633

Мин 31 яшьлек авыл егете. Буем 170 см. Аракы эчмим. Бер эштән дә курыкмыйм. Махсус урта белемле. Механизатор булып эшлим. Әти-әниебез белән авылда, үз йортыбызда яшибез. Киләчәктә бергә гаилә корып, бер-береңне аңлап, саклап яшәр өчен 25-30 яшьләрдәге, авылда яшәргә риза булган кыз белән танышырга телим. Килгән барлык хатларга җавап бирәм.

### ММ-635

Миңа 26 яшь, буем 165 см. Урта белемле, ябыграк гәүдәле өйләнмәгән татар егете. Казаннан 50 км ераклыктагы бер авылда яшим һәм эшлим. "Игезәкләр" йолдызлыгы астында туганмын. Начар гадәтләрем юк, аракы эчмим, тәмәке тартмыйм. Тыныч холыклы, хатын-кызга хөрмәт белән карый белүче ир-егетмен. Хуҗалык эшләрен җиренә җиткереп башкарырга яратам. Буш вакытларымда баянда уйныйм. 20-32 яшьләрдәге, тыйнак, сабыр холыклы, үзем кебек ялгызлыктан туйган берәр татар кызы белән танышып, гаилә корып яшәргә телим. Үземә тиң ярның берәр кыз баласы булуы да куркытмый. Хат языгыз, үкенмәссез.

### КФ-637

Мне 22 года, татарин, спортивного телосложения, без дурных привычек. Хочу познакомиться с девушкой-татаркой до 23 лет, ростом не выше 170 см. Желательно в письме отправить фотографию, которую обязуюсь вернуть.

### СМ-498

Калган тормышымда терәк була алырлык, акыллы, тыныч, буе-сыны килешле, 35-45 яшьләрдәге ир-ат миңа хат язып җибәрә ала. Ә инде ул кеше шат күңелле, баянда уйнап, күңелле итеп яши белсә, мине үзенә якын итсә, бу зур бәхет булачак. Үзем Татарстанның зур бер шәһәрендә үз фатирымда яшим. Буем 167 см. "Ир-ат күзе төшәрлек" чибәр генә ханым. Килгән фотосурәтләрне кире кайтарам.

### ГФ-639

Көн артыннан көн үтә, ә мин һаман көтәм. Очрарсың кебек. Кайда, кайчан? Анысын Алла гына белә. Үзем турында нәрсә генә языйм инде? Гади татар егете. Авылда яшим. 24 яшьтә, уртача буйлы, блондин. Әгәр син эчкерсез, ачык һәм намуслы булсаң, хат яз миңа. Фоторәсемеңне дә җибәр. Җавап бирермен.

### ГР-500

Миңа 38 яшь, буем 156 см. Авылда әти, әни, энеләрем белән яшим. Матурлыгым белән мактана алмыйм, уртача. Үзем кебек ялгызлыктан интеккән, алдагы тормышымда таяныч, ялгыз чагымда иптәш булырдай, аракы эчү белән артык мавыкмый торган 35-45 яшьләрдәге ир-егет белән танышыр идем. Килгән фотосурәтләрне кире кайтарам.

### ВИ-641

Миңа 43 яшь, буем 175 см. Белемем югары. Казанда үз фатирымда яшим. Хатыным авырып үлде. 8 яшьлек улыма әни, үземә алдагы тормышымда иптәш булырлык, татар яки башкорт милләтеннән булган 30-40 яшьләрдәге ялгыз хатын-кыз белән танышыр идем. Килгән фоторәсемнәрне кире кайтарам.

### БР-643

Миңа 33 яшь, буем 168 см. Милләтем татар. Авылда туып-үстем. Хәзерге вакытта Уфа шәһәрендә заводта эшлим, тулай торакта яшим. Өйләнгәнем булмады. Гаилә кору максатында үземә тиң булырдай хатын-кыз белән танышыр идем.

### ТӘ-645

Миңа 30 яшь, буем 165 см. Өйләнмәгән татар егете. Авылда яшим, колхозда балта остасы булып эшлим. Начар гадәтләрем юк, аракы эчмим, тәмәке тартмыйм. Әнием белән үз йортыбызда яшибез. Гаилә кору максатында 20-28 яшьләрдәге, авылда яшәргә риза булган кыз белән танышыр идем. Сагынып хат көтеп калам.

### АС-502

Миңа 46 яшь, буем 158 см. Милләтем татар. Тәскә-биткә матур, ачык йөзле, уңган, шат күңелле, уртача гәүдәле, кешеләргә ихтирамлы. Ирем вафат булды. Төпле уйлы, эш сөючән, сабыр холыклы, ышанычлы, киң күңелле, гаиләдә бер-береңне аңлап, хөрмәт итеп, бер-береңә таяныч булып яшәрлек, 46-50 яшьләрдәге, сау-сәламәт ир-ат белән танышырга телим. Хат язучылар Әлмәт районыннан булса, әйбәтрәк булыр иде. Килгән фоторәсемнәрне кире кайтарам.

Е. Канаев фотосы.

---

10 ваучерны яхшы хәлдәге "Жигули" яки "Москвич" автомобиленә алмаштырам.

**Адрес: Татарстан, Азнакай районы, Актүбә поселогы, М.Җәлил урамы, 5-4. САФИН.**

* * *

Улым башка балалар кебек сау-сәламәт иде. 4 яшь тулгач, үзгәрешләр сизә башладык. Еш егыла, авыр йөри башлады. Врачлар "мускуллар хәлсезлеге" дигән диагноз куйдылар. Хәзер аңа 10 яшь, елдан-ел начарланып, хәзер бөтенләй йөрми башлады. Бәлки бу чирнең дәвасын белүчеләр бардыр? Газета укучылар арасында улымны дәваларга ярдәм итүчеләр булмас микән? Сезнең киңәшләрегезне көтеп калам.

**Адрес: 423550, Татарстан, Түбән Кама шәһәре, Тихая Аллея урамы, 3-40. Ф.МӘҮЛӘВИЕВА.**

* * *

8 ваучерны яңа "Урал" мотоциклына яки мотороллерга алмаштырабыз.

**Адрес: Татарстан, Мөслим районы, Иске Карамалы авылы, Кооператив урамы, 35. МӘҮЛИЕВ.**

* * *

Безнең 5 яшьлек улыбыз чирле: йөри алмый. Диагнозы - "балалар церебраль пэраличы". Үзе *бик акыллы,* хәрефләр таный, саный белә, сөйләшә. Бу авыруны кайда дәвалап була икән? Бәлкем, шушы чирдән терелүчеләр, атлап китүчеләр бардыр, кайда дәвалагандылар икән? Белүчеләр булса, язып җибәрүегезне үтенәм.

**Адрес: 452600, Башкортостан, Туймазы шәһәре, Мичурин урамы, 8-5. Гүзәл ХАҖИЕВА.**

* * *

Җиләк-җимеш, бал, дару үләннәре белән төрле чирләрне дәвалау буенча һәрбер чиргә берничә рецепт тәкъдим итәм. Рецептлар алу өчен түбәндәге адрес буенча 120 сум акча күчерү турында квитанция һәм җавап язу өчен конверт салуыгыз сорала.

**Адрес: 452607, Башкортостан, Туймазы районы, Уязытамак авылы. Ф.ХӘЙРУЛЛИН.**

* * *

Берничә ваучерны яңа "Иж-Планета" яки "Иж-Юпитер" мотоциклына алмаштырам.

**Адрес: 422950, Татарстан, Чистай шәһәре, Свердлов урамы, 79. Зөфәр ТӘХВӘТУЛЛИН.**

* * *

5 ваучерны яңа "Иж-Планета" яки "Иж-Юпитер" мотоциклына алмаштырам.

**Адрес: 422330, Татарстан, Кайбыч районы, Олы Кайбыч районы. Габдулла ГАБДУЛГАНИЕВ.**

ТЯ

Баш мөхәррир
Исмәгыйль ШӘРӘФИЕВ
(53-52-34)

ЯЗЫГЫЗ:
420066, Казан, Декабристлар урамы,2.
"Татарстан яшьләре"

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
53-07-52 - баш мөхәррир урынбасары
53-07-50 - җаваплы сәркатип,реклама
53-07-58 - хатлар бүлеге
53-07-54 - сәяси тормыш һәм тәрҗемә, фән һәм мәгариф
53-07-56 - мәдәният-сәнгать
53-07-52 - табигать, авыл тормышы

"Татарстан яшьләре"н гамәлгә куючылар - ВЛКСМның республика оешмасы, Татарстан Республикасының Яшьләр оешмалары советы, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы.

Газета Татарстан республикасының Матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 4-нче номерлы таныклык белән теркәлде.

"Т.Я" сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

*Редакциянең исәп-хисап счеты:*
*Р/с 700161998/700751*
*ВКАБ РКЦ ГЦБ г.Казани, МФО 265005*
*Индекс - 54121*
*Тираж - 200.000*

Татарстан газета-журналлар басмаханәсе. Газета басылуга кул куюю график буенча 18 сәгатьтә. Бу санга 14 сәгатьтә кул куелды. Заказ 6044